НИ КӨТӘРГӘ?

«ВТ» хәбәрчесенең дөньядагы вакыйгаларга карашы

> 2

БЕР САВЫТКА

Нурлат районының Нариман авылы халкы кеше башыннан 38 мең сум үзара салым акчасы җыйган

> 2



МАЛ ЯРАТУ

22 яшьлек Игорь Гордеев унҗиде сыер сава

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Бездә кунакта – Арча районының Наласа урта мәктәбе укучылары

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 172 (29139) | Чәршәмбе | 22 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Юл хәлләре

Беренче кар! Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов юлдагыларны бер төндә көздән кышка аяк басу уңаеннан котлады. Баксаң, юлчылар табигатьнең мондый кылanмышына әзер булган. Көттереп, әмма буранлап яуган кар аркасында республикада гадәттән тыш хәл килеп чыкмаган. Татарстан Хөкүмәт йортында юл хезмәте оешмаларының кышкы чорда әзерлегенә багышланган һәм алдан ук билгеләнгән брифингта беренче сынау нәтиҗәләре турында сөйләштеләр.

– Быел тагын да күбрәк юллар төзелде, димәк, җаваплылык та артты, – диде Фәрит Хәнифов сүзне еракtan ук башлап. – Узган атнада Татарстанда М12 югары тизлекле трассасының бер өлеше кулланышка тапшырылды. Ул 20 декабрьдә тулысынча ачылыр дип көтелә. Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлын төзү кысасында Чулман елгасы аша салынучы күпернең 18 торыгында (алар барлыгы 22. – **Ред.**) эш тәмамланды. Моннан тыш, Шәле – Баулы автомобиль юлы төзелешендә эш дәвам итә.

Министр сүзләренә караганда, быел Татарстанда 210 миллиард сумлык юл эшләре башкарылган. Аңлашыла ки, аның шактый өлеше М12 югары тизлекле трассасы төзелешенә туры килгән. Төбәк дәрәҗәсендәге программалар кысасында юлларга 81,1 миллиард сумнан күбрәк акча «түшәгәннәр».

– Соңгы елларда республикада зур юллар төзегәндә муниципаль дәрәҗәдәге, авыллар арасындагы бер мең чакрымга якын озынлыктагы юл файдаланылды. Алар шактый таушалды. Зур трассалар салынып беткәч, киләсе елда әнә шул кечкенә юлларда ремонт башларга ниятлибез, – дип тә алдан ук тынычландырды Фәрит Хәнифов.

Кышкы чорда мондый ямаулы юлларга игътибарны арттырырга да киңәш итте ул. Юлчыларга уяулыкны югалтырга ярамый. Татарстан башкаласында дүшәмбедән сишәмбегә каршы төндә айлык норманың чирек өлеше кадәр кар яуган әнә. Гомумән алганда, Татарстан юлчылары кышка әзер, дип хисап тотты министр. Олы юлларны кардан вакытында арындыру өчен 1,1 меңнән артык техника, 473 мең тоннага якын тоз-ком катнашмасы һәм 97 мең тонна техник тоз әзерләп куйганнар.

Федераль дәрәҗәдәге юлларның торышы да шик уятырлык түгел.

– Федераль трассаларда юл һәм һава торышына бәйле вазгыятьне 44 метеостанция контрольдә тота, – диде Юл федераль агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе җитәкчесе Илдар Минһаҗев. – Алардан алынган мәгълүмат ярдәмендә алдагы 2–4 сәгатькә һава шартларын тәгаен фаразларга һәм кирәк очракта, Дәүләт автоинспекциясе белән берлектә юлларда хәрәкәтне вакытлыча чикләү турында карар кабул итәргә мөмкин. Сишәмбегә каршы төндә, һава торышы кискен үзгәрү сәбәпле, автобуслар һәм, йөк машиналары өчен хәрәкәт якынча сигез сәгатькә туктатылып торды инде.

Ә менә Казанда кар көрәүчеләр җитми. Бу хакта шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасары Игорь Куляжев әйтте. Аның сүзләренә караганда, башкаланың юл хезмәте предприятиеләрендә кадрлар кытлыгы сизелә.

– Хезмәт хаклары түбән булу аркасында мәсьәләне тулысынча хәл итеп бетереп булмый, – диде ул, кулына көрәк алырга әзер булучыларның ни өчен җитмәвенә ишарәләп. – Юлларны тәртиптә тотуда эшчеләр аз булу сәбәпле, аларны кышкы чорда эш кимрәк булган урыннардан да җәлеп итәбез. Сменалап эшләргә туры килә. Кышкы режимга күчкәч, хезмәт хаклары да бераз арта, билгеле. Төнлә һәм ялларда да эшләүне исәпкә алып, юл хезмәткәрләре уртача – 47, машина йөртүчеләр 80 мең сум хезмәт хакы алачак. Бүген тармакта эшләүчеләрнең уртача яше – 50–54.

Казанда тәртиптә тотарга кирәкле юлларның гомуми мәйданы 22,7 миллион квадрат метр тәшкил итә. Быел гына да әлеге күрсәткеч 570 мең квадрат метрга арткан. Яңа салынган юллар турында сүз чыккач, Фәрит Хәнифовтан Вознесение трактының икенче өлеше кайчан салынып бетәчәген дә сорадылар. «Быел әлеге төзелеш буенча финанслау 7 миллиард сум тәшкил итте. Барлыгы исә 20 миллиард сум чамасы акча кирәк. Шуңа күрә эш тә, финанслау чыганакларын эзләү дә киләсе елда дәвам иттереләчәк», – диде министр.

Әлегә исә булган юлларда исән-имин йөрергә язсын!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КӨРӘККӘ КЕМ ХУҖА?

Бер түләсәң, җитә

М12 югары тизлекле юлында, шул исәптән аның Татарстанга туры килгән өлешендә дә иминлек сагында юлчылар гына түгел, авария комиссарлары хезмәте дә сакта торачак. «Автодор» дәүләт корпорациясенең эксплуатацияләү буенча идарә рәисе урынбасары Геннадий Жилин сүзләренә караганда, яңа юлда куркынычсызлык мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирелә. «Юл чатында туктап калган машина да авария китереп чыгарырга мөмкин», – диде ул. Шуңа күрә югары тизлекле трассада авария комиссарлары кизү торачак. Алар ялларсыз һәм тәүлек әйләнәсе эшләячәк.

– Ярдәм егерме минутта килеп җитәчәк, – диде Геннадий Жилин. – Комиссарлар машинага ягулык салу, техник хезмәт, медицина ярдәме күрсәтү, гадәттән тыш хәл урынына махсус хезмәтләрне чакырту, автомобильне эвакуацияләү, юл инфраструктурасын тәртиптә тоту кебек бурычларны башкарачак. М12 трассасында барлыгы 27 экипаж эшләячәк. Аларның алтысы – Татарстанда. Билгеле булганча, М12 трассасы түләүле. Юлда авария комиссарын чакырткан өчен машина йөртүче өстәп акча түләмәячәк.

Студентларга – яңа үзәкләр

Студентларның хәрби әзерлеген камилләштерү өчен, Россиянең барлык төбәкләрендә хәрби укыту үзәкләре ачылачак. Оборона министры Сергей Шойгу әйтүенчә, хәзерге вакытта 9 югары уку йорты (шул исәптән Луганск Халык Республикасында) мондый үзәкләр ачылырга тора.

Шойгу сүзләренә караганда, хәрби әзерлек белән шөгыльләнүче төбәкләр саны – 82, ә хәрби укыту үзәкләре саны 137гә җитәчәк. Министр билгеләп үткәнчә, гадәти югары уку йортлары да махсус хәрби операция максатына ирешүгә үзләреннән зур өлеш кертә. Әйтик, илнең 400дән артыграк вузыннан 20 меңгә якын студент волонтерлык эшчәнлегендә һәм гуманитар миссияләрдә катнаша.

Авыл йорты кызыктыра

Татарстанда 4 меңләп гаилә «Авыл ипотекасы» программасы буенча салада йортлы булган. Бу программа бездә инде 3 елдан артыграк вакыт дәвамында гамәлгә ашырылып килә. Росреестрның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Азат Җаббаров әйтүенчә, шушы чорда 10 миллиард сумнан артыграк кредит бирелгән. Бер ипотека күләме уртача 2,5 миллион сум тәшкил итә.

Акча башлыча авылларда әзер йортлар сатып алуга тотылган. Шулай ук «Авыл ипотекасы» буенча үзеңнең җир кишәрлегеңдә шәхси йорт төзетергә яки йорт салу өчен җир кишәрлеге сатып алырга мөмкин. Бу елдан башлап, акчаны билгеле бер бистәләрдә (кечерәк район үзәкләрендә) төзелеп килүче яки әзер яңа йорттан (5 каттан биек булмаска тиеш) фатир сатып алуга да тотарга мөмкин. Әйтик, хәзерге вакытта Буа һәм Арчада шундый торак сатып алу мөмкинлеге бар.

Азат Җаббаров сүзләренә караганда, авыл ипотекасы Татарстанда ипотека базарын, шулай ук саланы үстерүгә өстәмә этәргеч биргән.

Тагын арта

Россиядә узган атнада (13–19 ноябрь) барлыгы 58159 кешедә коронавирус табылган. Ковидка каршы көрәш буенча федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, 82 төбәктә чирләүчеләр арткан. Татарстанда бер атна эчендә чир йоктыруның 596 очрагы ачыкланган.

Узган атнада илдә барлыгы 6398 кешене хастаханәгә салганнар. Мондыйлар саны алдагы атнадагыга караганда 16,9 процентка арткан. Хасталарның күбәюе 55 төбәктә күзәтелгән. Татарстанда исә бер атна эчендә 188 кешене дәвалау оешмасына озатканнар.

Шушы чорда җәмгысы 39731 кеше савыккан. Алдагы атнадагыга караганда 32,5 процентка күбрәк сан бу. 93 кеше вафат булган. Татарстанда исә 361 кеше савыккан. Республикада быел гыйнвар уртасыннан бирле үлем-китем очраклары юк.

Борчыган мәсьәлә

Үзен дә сакларга кирәк

Кеше гомере, сәламәтлеге сагында торган табибларның үзләрен дә сакларга кирәк! Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов шундый тәкъдим белән чыкты. «Россия медицинасы» басмасына биргән әңгәмәсендә ул, медицина тармагында эшләүчеләргә әледән-әле һөҗүм итүләрен, аларның закон тарафыннан якланмаган булуын әйтте.

– Бүген хәтта хайваннарны кыерсыткан өчен дә катгыйрак чаралар күрелә. Күптән түгел Әлмәттә аянычлы очрак күзәтелде. Баласын тиз арада кабул итмәгән өчен, ир-ат отоларингологка кул күтәрде һәм бу гамәле өчен ул нибары 5 мең сум штраф түләп котылды, – ди депутат. – Шуңа күрә табибларга һөҗүм иткән өчен җәзаны көчәйтергә кирәк. Табиб үзе беркайчан да махсус органнарга барып, зарланып йөрмәячәк. Аның моңа вакыты да юк. Кадрлар кытлыгы аркасында, бүген табибларга болай да бөтен көчен куеп эшләргә туры килә.

Табибларга һөҗүм итү очраклары әледән-әле күзәтелеп тора. Октябрь башында Түбән Новгород өлкәсендә бер авыру реанимация бүлеге мөдирен кыйнаган иде. Аңа кадәр Саратовта «ашыгыч ярдәм» хезмәтендә эшләүче табибка пычак белән һөҗүм иттеләр. Комсомольск-на-Амуре шәһәрендә дә шундый ук хәл булды. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, соңгы ярты елда илдә табибларга һөҗүм итүнең 820 очрагы теркәлгән.

Казандагы шәхси оешмаларның берсендә терапевт булып эшләүче Алия Насыйбуллина да, медицина хезмәткәрләре күптән закон тарафыннан яклауга мохтаҗ, дип саный. Эш вакытында аның да куркыныч хәлләргә тарыганы булган.

– Укып бетергәч тә, Казандагы сырхауханәләрнең берсендә эшләдем. Өйдән-өйгә дә күп йөрергә туры килде. Шулай бервакыт ишекне наркоман ачты. Йөзенә карарлык түгел. Әнисенең хәле авырайгач, табиб чакырган. Ничек чыгып чапканымны да белмим. Янымда берәр ир кеше булса, курыкмыйча кергән булыр идем инде. Хастаханәнең кабул итү бүлегендә эшләгәндә дә исерекләр бәйләнгән, янаган чаклар булды. Әнә шул күренешләрдән туеп, шәхси оешмага эшкә күчәргә булдым да инде. Медицинада кадрларга болай да кытлык. Аларның якланмаган булуы хәлне тагын да катлауландыра, – ди Алия.

Казанның 1 нче ашыгыч ярдәм подстанциясе фельдшеры Рузилә Сафинага утыз ел эшләү дәвамында төрлесен күрергә туры килгән.

– Участок инспекторлары кебек безгә дә төрле кеше белән эшләргә туры килә. Араларында исерege дә, психик авырулары, наркоманы да очрый. Аларга ярдәм иткәннән соң, булыша алуыңа бер шөкер итсәң, исән калуыңа тагын бер сөенәсең. Бер үк кешеләр белән эшләсәк тә, участок инспекторларыннан аермалы буларак, безгә һөҗүм иткән өчен закон тарафыннан тиешле җәза каралмаган. Бу җитешсезлекне күптән төзәтергә вакыт, – ди Рузилә ханым.

Сүзгә-сүз

realnoevremya.ru/М. Платонов

Олег ГРИГОРЬЕВ, Татарстанның Киңлекне планлаштыру институты директоры:

Әгәр бернәрсәне дә үзгәртмәсәк, транспортка бәйле вазгыять тагын да начараячак. Болай дәвам итсә, 2050 елда 1 мең кешегә якынча 600 машина туры киләчәк. Мондый шартларда күпме генә кыйммәтле юллар төзелсә дә, үзгәреш булмаячак. Шуңа күрә эре шәһәрләр һәм аның тирәсендә җәмәгать транспортын мөмкин кадәр үстерергә кирәк.

(«Реальное время» басмасыннан)

РОССИЯДӘ – ХЕЗМӘТ ХАКЫ

FinExpertiza һәм Росстат белгечләре югары хезмәт хакы алучы һөнәр ияләрен ачыклаган.

КЕМГӘ КҮПМЕ ТҮЛИЛӘР? (аена, сумнарда)

ИҢ КҮБЕ	Нефть һәм газ тармагы хезмәткәрләре	176,7 мең
	Финансистлар һәм иминият белгечләре	155,5 мең
	Авиация тармагы хезмәткәрләре	151,9 мең
ИҢ АЗЫ	Китереп бирү тармагы (курьер, почтальон)	39,9 мең
	Кием-салым җитештерү вәкилләре	33,5 мең
	Җәмәгать туклануы вәкилләре	39,1 мең

Беркатлылык бәласе

Узган елларда республикада 10 кеше һәм 1 оешма мошенниклар корбанына әйләнгән. Чаллыдан – 4, Казан һәм Әлмәттән – 2шәр, Яңа Чишмә, Нурлат районнарыннан – 1әр кеше, Бөгелмәнең 1 компаниясе кырыгалдарлар кармагына эләккән, дип хәбәр итә Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте.

Чаллыда 74 яшьлек хатын-кыз, кызының авариягә эләгүенә ышанган һәм мәсьәләне хәл итүгә өметләнеп, курьерга 1,5 миллион сум акча биреп җибәргән.

Аферистлар кешеләрне алар алмаган кредиттан коткарырга вәгъдә итеп тә алдый. Чаллыда 61 яшьлек ханым 17 көн буе телефон аша мошенниклар белән аралашкан. Аның исеменә кемнәрнеңдер кредит рәсмиләштерергә маташуына ышандырып, моңа юл куймас өчен, кредит алып, акчаны «махсус» счетларга күчерергә күндергәннәр. Шулай итеп, пенсионер барлыгы 4119000 сум заем акчасы алып, шуны кырыгалдарлар счетына күчереп куйган.

Тиз генә баеп китмәкче булып, киресенчә, акчасыннан мәхрүм калучылар да бар. Яңа Чишмә авылында 1966 елгы пенсионер ханым, миллионнар эшләргә хыялланып, 16 көн эчендә 3 миллион сум акчасын югалткан. Хәтта акчаны кемнәрнеңдер телефон номерына гына күчерү дә аңарда бернинди шик тудырмаган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ИСТАНБУЛДА СУ БЕТӘ

Үткән атнада Си Цзиньпин белән Байденның Сан-Францискода АТЭС саммиты кысасында булып узган очрашуы көтелгән нәтиҗәләрне бирмәде. Халыкара көндәлек бизнес яңалыклары газетасы Financial Times ике держава лидерларының очрашуы «алар арасында үзара ышаныч юклыгын күрсәтте» дип билгеләп үтте.

Очрашуда ике илнең үзара якынаюы, Украинадагы һәм Фәләстыйндагы хәлләргә уртак бәя бирү, үзара санкцияләрдән баш тарту булыр дип көтелгән иде. Халыкара мәгълүмат кыры очрашуны «берни дә барып чыкмады» дип бәяләде. Шуңа күрә вакыйга мәгълүмат кырында икенче планда калды, артык яктыртылмады. Аргентинаның яңа Президенты Хавьер Милейның пьедесталга менүе, мәсәлән, игътибарны күбрәк җәлеп итте. Илон Маск бу уңайдан: «Аргентинаны чәчәк ату көтә», – диде. Милей әлегә үзен чын юләрләрчә тота: ямьсез итеп сүгенә, этләренең төп киңәшчеләре булуын белдерә, Кытай белән (һәм, гомумән, коммунистлар белән) эш итмәячәген әйтә… Соңгы белдерү принципиаль әһәмияткә ия, чөнки чиннар дефолт хәленә килгән Аргентинаны күп миллиардлаган суммалар белән терәгән иде. Милей сүзендә торса, Пекинга барлык бирәчәген дә кичерер, мөгаен, ягъни бурычларга дефолт игълан итәр. Этләр белән киңәшүче Президентның популярлыгы – бүген югары ноктада. Салымнарны 90 процентка киметергә вәгъдә бирүе белән генә дә ул миллионнарның йөрәген яулады. Аны «икенче Трамп» дип тә йөртәләр, әмма Трампны Милей белән чагыштырырлык та түгел. Үтә уңнар белән сулларның алышынып торуы – Латин Америкасы өчен гадәти күренеш. Чикләнмәгән ирекләр вәгъдә итүче Президент идарәсенең ни белән тәмамлануын, исән булсак, дүрт елдан соң күрербез.

Дөньяда глобаль финанс һәм икътисад кризисы белән көрәшү өчен майданга тилемсә лидерлар чыккан вакытта тагын бер кризис – су кризисы көчәя. Төркиянең авыл хуҗалыгы министры Ибраһим Юмаклы 2030 елга илдә су җитми башлаячагын игълан итте. Су җан башына 1000 кубометрдан кимрәк булачак икән. Бу фараз ил халкының яртысын, сугарулы авыл хуҗалыгы җирләренең 80 процентын кыен хәлгә куя. Хәл чынлап та җитди, күрәсең. Климат буенча белгеч Ләвәнт Курназ, Истанбулдагы вазгыятьнең ни дәрәҗәдә кискен булуын ассызыклап, ахыр чиктә шәһәрдәге халык санын чикләргә кирәк булачагын әйтә. Быел ук инде Истанбул буаларында октябрь уртасында су күләме рекордлы 16,8 процентка кимегән. Соңгы көннәрдә яуган яңгырлар гына аны 22,63 процентка күтәргән. Британ порталы The Arab Weekly, соңгы егерме елда Төркиядәге 320 күлнең 60 проценты кипкән, дип яза. Проблема бер төрекләр өчен генә хас булса, хәвеф масштабына түзәр идең. Глобаль су кытлыгы планетаның күп төбәкләренә яный.

Россиядә

НАЧАР БУЛГАН САЕН ЯХШЫРА

Россиядәге финанс-икътисад хәлен язма исемендәге сүзләр белән бәяләп булыр иде, мөгаен. Көнбатышның «җәһәннәм санкцияләре» көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Моны алар үзләре дә таный.

Ел башында зур тишеккә әверелеп, бюджетны ертырга вәгъдә иткән дефицит, ел ахырына кимеп, планлаштырылган кысага керде. Статистика хезмәт хакларының, инфляцияне узып, югары сикерүен хәбәр итә. Рәсми саннарга карасаң, россиялеләрнең матди хәле көннән-көн яхшыра. Хәер, монысын һәркем үз кесәсе ярәмендә бәяли ала. Газета хәбәрчесенең финанс мөмкинлекләре, мәсәлән, алай югары сикермәде: элек сатып ала алмаган нәрсәләрне але дә ала алмый.

Кайбер икътисад күрсәткечләренә күз салсак, язма исемендәге сүзләрне киресенә әйләндерәп тә укып була: яхшырган саен начарая. Казнаның хәле яхшыра, ә эре компанияләрнеке начарая. Хезмәт хаклары зур темплар белән үсүгә карамастан, халык бурычка тирәнгәрәк бата бара. Россиялеләр еллык 300 процент ставка белән микрокредитларны 350 миллиард сумга җыйды, ди микрофинанс базары белгечләре. Микрофинанс оешмаларына кеше кайчан бара? Банкларда бернинчә кредит җыеп, түли алмаслык хәлгә килгәч. Банк бирми, микрокредитны бирәләр. Ил халкының 7,9 миллионы коммуналь түләүләр буенча бурычка баткан. Моның гаиләләр саны икәнен аңласак, якынча 20 миллион тирәсе кеше ут-су, газ өчен түли алмый, дип әйтергә була.

Халык кына түгел, компанияләр дә бурыч үстерә. Аларның бурычы, ел башыннан 16 процентка артып, августка 103 триллион сумга җиткән. Бюджетның төп чишмәләреннән берсе булган «Газпром» авыр көннәр кичерә. Өченче кварталда табигый монополия 85 миллиард сумлык зыян күргән. Керемнәре 36 процентка кимегән. Дәүләт Думасында «Газпром» 2025 елда 1 триллион сумлык зыян күрәчәген фаразлыйлар. Халыкара энергетика агентлыгы, 2030 елга дөньяның газ базарында Россия монополиясенең өлеше ике тапкыр кимер, дип вәгъдә итә.

«Газпром» белән ТКХ арасында турыдан-туры бәйләнеш барлыгын аңлыйсыздыр инде. Белгечләр, 2024 елда торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр 10–11 процентка артыр, диләр. Росстат халыкның реаль керемнәре кызу темплар белән үсә дип расласа, суд приставлары бурычлы 7,9 миллион кешенең хәлен реаль керемнәр кимү белән аңлата.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ТИЗРӘК ҺӘМ КҮБРӘК

ЯШЕЛ ҮЗӘНДӘ «ОЗОН» ТАРАТУ ҮЗӘГЕНЕҢ ИКЕНЧЕ ӨЛЕШЕ АЧЫЛДЫ

Онлайн сатып алулар белән дус булучыларга сөенче: «Озон» маркетплейсыннан заказ белән китерелә торган товарлар хуҗасына тагын да тизрәк киләчәк. Яшел Үзәндә «Озон» тарату үзәгенең икенче өлеше ачылды. Ачылыш тантанасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.

tatarstan.ru

Үзәкнең мөмкинлекләренә күз салыйк. Логистик үзәк төзелеше белән, товарларны саклау мәйданчыгы икеләтә артачак (23 мең квадрат метрдан 43кә җитәчәк). Үзәктә 10 млн товарны урнаштырырга мөмкин булачак. Барлыгы 2 меңләп кешегә яңа эш урыны булачак.

Яшел Үзәннән көн саен 200 меңләп посылка (345 меңгә дә җитә) җибәрелә. Тарату үзәгенең икенчесен ачудан тыш, өченчесен дә төзү бара. Анысы да кулланылышка тапшырылгач, объектның мәйданы 84 мең квадрат метрга җитәчәк.

Татарстан территориясендә тормышка ашырылган проектлар өчен Рөстәм Миңнеханов «Озон» компаниясенә рәхмәтен җиткерде.

– Бүген мөһим көн – «Озон»ның икенче өлешен ачабыз. Татарстанда электрон сәүдә үсеше бик зур, моның белән бергә клиентларга хезмәт күрсәтү сыйфаты да арта. 8 меңләп татарстанлы үз продукциясен «Озон» аша сата, – диде Татарстан Рәисе.

«Озон»ның идарәче директоры Сергей Беляков Татарстанны бизнес белән җитәкчелекнең аңлашып эшләү үрнәге дип атады.

– Мондый хезмәттәшлек бәрабәренә республикада сатучылар да, заказны куллануучыга тапшыру пунктларын ачучылар да икеләтә арта. Без эшкуарлыкны үстерү мәсьәләсендә төбәкнең алдынгы карашын ихтирам итәбез, шуңа күрә кече һәм урта бизнеска ярдәмне арттырабыз. Республикада инде 1 меңнән артык заказ тапшыру пункты эшли, – диде ул.

ВЭБ.РФның шәһәр үсеше буенча баш идарәче партнеры Ирина Макиева да Татарстанда әйтелгәннең үтәлүен әйтте.

– Кайчандыр без Рөстәм Нургалиевич белән Яшел Үзәнгә килгәндә логистика үзәге буласы урында ялан кыр иде. Республика бу урында сәнәгать шәһәре үсеп чыгасын вәгъдә итте. Татарстанда әйткәннең барысы да тормышка аша, – диде ул.

Сан

2023 елның тугыз ае йомгаклары буенча, үз товарларын маркетплейсларда сатучы татарстанлылар саны 55 мең 919га җиткән (үсеш +35 процент). Башкача әйткәндә, бу – Татарстанда теркәлгән юридик затларның һәм үзмәшгульләрнең 12 проценты. Беренчел фаразлар буенча, аларның кереме 46 млрд сумны тәшкил иткән.

УРТАК КЫЙММӘТЛӘР

Традицион кыйммәтләрне саклау һәм ныгыту. Казанда узган православие җәмәгатьчелеге форумының да төп сүз әнә шул хакта булды. Форумның пленар утырышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Рөстәм Миңнеханов форумдагы чыгышында бердәмлек һәм берләшү мәсьәләсенә тукталды.

– Әлеге чара илебез өчен авыр вакытта уза. Яңа бурычлар бездән түземлек тә, бердәмлек тә, рухи кыйммәтләрне яклауда тәвәккәллек тә сорый. Мондый шартларда республика җәмәгатьчелеге дә, православие руханилары да бердәмлек, фикерләр уртаклыгын, хезмәттәшлеккә омтылыш үрнәген күрсәтә, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Быелгы форум Казан православ руханилар семинариясенең 300 еллыгына багышланган. Бу уку йорты бик танылган, ул Казан өчен генә түгел, бөтен ил өчен дә белгечләр әзерләгән.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, дин белгечләрен әзерләүдә традицион кыйммәтләргә таяналар. Дәүләт традицион рухи кыйммәтләрне саклау һәм үстерү өчен барлык шартларны тудырырга тырыша.

Татарстан Рәисе сүзләренә караганда, традицион гаилә кыйммәтләрен, сәламәт яшәү рәвешен ныгыту, ватанпәрвәрлекне пропагандалау, радикализм һәм экстремизмга каршы тору белән бергә бүген махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү эшен бергә алып барырга кирәк. «Республика җитәкчелеге алга таба да сезнең ярдәм һәм теләктәшлеккә өметләнә», – диде ул катнашучыларга.

Юбилей форумы катнашучыларына рәсми тәбрикләү хатын Мәскәү һәм бөтен Русь патриархы Кирилл да җибәрде.

– Россия бүген катлаулы чор кичерә, һәм без барыбыз да бердәмлек күрсәтергә тиеш. Әлеге форум Татарстан җирендә дин һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрне уңышлы дәвам иттерүгә булышыр, илебездә дини белем бирүне үстерүгә зур өлеш кертер дип өметләнәм, – диелә мөрәҗәгатьтә.

Үтенеч һәм рәхмәт сүзләре

Авыл күлен чистарту, бистә юлын төзекләндерү, урамнарны яктырту. Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшинга партия Рәисе Дмитрий Медведевның төбәк иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә шундый мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иттеләр.

Лаеш районыннан Татьяна Гусева телефон аша Каип авылындагы күлне чистарту һәм төзекләндерү буенча ярдәм сорады. Аның әйтүенчә, авыл халкы район хакимиятенә бу хакта мөрәҗәгать иткән, әмма мәсьәлә хәл ителмичә калган. Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, күлне төзекләндерү мәсьәләсе, «Бердәм Россия»нең Халык программасы кысасында, сайлаучылар наказлары исемлегенә кертелгән. «Күлне кадастр учетына кую эшләре тәгәлләнгән. Хәзер аны су объектлары исемлегенә кертү эшләре башкарыла. Соңыннан, күлне чистартуга акча юнәтү өчен, проект-смета документларын эшләү, дәүләт экспертизасы алу күздә тотыла», – дип аңлатты парламент башлыгы.

Әлмәттә яшәүче Тимур Алимовның исә бистә юлын төзекләндерү мәсьәләсе борчый. Аның әйтүенчә, 100ләп гаилә яшәгән бистәдә урамнар да яктыртылмаган, үзәктән су белән тәэмин итү дә каралмаган, тротуарлар да юк. Фәрит Мөхәммәтшин, бу мәсьәлә буенча шәһәр хакимияте белән сөйләшеп, бистәне төзекләндерү эшләре планына кертү мөмкинлеген карарга кирәклеген әйтте.

Ә менә Роспотребнадзорның «Татарстан Республикасы Гигиена һәм эпидемиология үзәге» оешмасы микробиологик тикшеренүләр бүлеге мөдире, сәясәт фәннәре докторы Гөлнара Бәдамшина республика җитәкчелегенә яшь галимнәргә ярдәм өчен рәхмәт сүзләрен ирештерде. Ул Россия Фәннәр академиясенә 300 ел тулуга багышланган Халыкара академик форумда катнашып, био- һәм медицина технологияләре буенча «Сәламәт буын» секциясендә икенче урынны алуы турында сөйләде.

КЕСӘ КАЛЫНГА ТҮГЕЛ…

Яшәеш

Авылларда үзара салым акчасы җыю буенча җыеннар уздыра башладылар. Кайсыдыр җирлектә тиеннәрне санап кына бирсәләр, ә кайдадыр халыкның юмартлыгына исең китә. Нурлат районының Нариман авылында узган ел кеше башыннан 38әр мең сум җыйганнар. Кызык, ничек шулай юмарт икән алар? Сәбәпләрен без җирлеккә барып белештек.

Туган авыл бит ул!

Нариман авылының табигате матур: тирә-ягы – урман, уртасында – күл. Бүген 15 йорт бар, әмма кышын анда берәү дә яшәми. Соңгы тапкыр биредә Ринат абый кыш чыккан. Әмма сәламәтлеге какшагач, ул да балалары янына киткән. Элек клуб, мәктәп, кибет, ферма – барысы да гөрләп торган. Бер генә бала укыса да, белем йортын саклаганнар. Тик бала-чагасы беткәч, мәктәп тә ябылган. Утыз ел элек 90лап кешесе булган әле Нариманның. Халкы юк, эш булмаганга күрә читкә таралышканнар. Шулай да нигезләренә сукмакны онытмый алар. Хәер, юлы әллә ни мактанырлык булмаса да. Моңа кадәр пычрак вакытта бөтенләй керә алмаганнар икән. Үзара салым программасы Нариман язмышын күпмедер үзгәртергә булышкан.

Тумышы белән шушы авылдан булган Радик Мифтахов Нурлатта яши. Аның әйтүенчә, туган авыл өчен акча җәл түгел. Иң мөһиме, файдасы тисен! Гомумән, ул акчаны күп дип тә санамый ул. «Наримнны бер дә бетерәсе килми шул. Кайткалап йөрибез. Юллар начар, шуңа күрә атна саен кайтып йөреп тә булмый. Туган нигезне карап торабыз үзе», – ди шофер Радик Мифтахов.

Рафис Шәрәфиев гаиләсе белән Әлки районында төпләнгән. Еш булмаса да, туган нигезенә кайткалый. Анда умарта тота икән.

– Туган авылда яшьлек үткән бит. Монда – әти-әни нигезе. Шуңа күрә бик кадерле ул. Без үзара салым акчасын сөенеп тапшырдык. Син бер өлеш бирсәң, дәүләт шуңа өстәп, дүртләтә арттырып кайтара. Файдасы тигәч, күңелгә өмет керә. Мондый ярдәм тагын кайда бар? Зиратны авылдашлар белән тәртиптә тотарга тырышабыз. Күлебез аяныч хәлдә: ләм утырган, агачлар ауган иде. Шуны казыдык, чистарттык, – ди эшмәкәр Рафис Шәрәфиев. – Юл булса, калыр идек, дисезме? Юл белән генә булмый шул. Эше дә, балаларга заманча мөмкинлеге дә кирәк. Элек бәрәңге ашап та яшәп була иде, хәзер алай түгел.

Файдасы тигәч…

Иске Әлмәт авылы башлыгы Равил Хисамов белдергәнчә, быел Нариманда унар мең сум акча җыярга дип килешкәннәр. Ә Иске Әлмәт җирлегендә – 1,5 мең. Бу акча юлларга таш җәю, күл казуга тотылачак. Быел җирлек 1,5 миллион сумлык республика грантын откан. Шуңа җәен трактор сатып алган алар. Җитмәгәненә 467 мең сум үзара салым акчасын өстәгәннәр. Трактор быел беренче карны эттерергә өлгергән дә инде. Үзара салым акчасын бирмичә калган кеше юк икән. Аннан I төркем инвалидлар һәм студентлар гына азат. 18 яше тулган һәм авылда пропискада торган һәркем әлеге бурычын үти. Җыенда һәрбер башкарган эш буенча хисап тота икән башлык. Аннан «Ватсап» төркеменә фотолар куя. Аларны читтә яшәүче авылдашлар да карый чөнки. Халыкка файдасын аңлата белергә кирәк, димәк. Ә болай алар каршы түгел икән.

– Нариман бетеп бара иде инде. Шулай бервакыт Мөхтәр хәзрәт Хәмитов: «Равил, мәчет төзесәк, ничек булыр икән? Безгә таркалмас, ямь кереп китәр иде», – дип киңәш сорады. Мин дә аның тәкъдимен хупладым. Шуннан соң үз акчасына шушы изге эшкә тотынды. Без дә ярдәм иттек. Авыл халкы хәер бирде. Үзган ел улы Илдар белән мәчет салдылар. Хәзрәт хак әйткән. Дөрестән дә, үзгәреш сизелә башлады бит. Киткәннәр авылга кайтып, иске йортларын буяргa, яңартырга, коеларын тазартырга тотындылар. Элек газ кертү өчен торбалар да сузылган иде. Әмма Нариманның киләчәге юк дип кермичә калды, – ди Равил Хисамов.

Иске Әлмәт авыл җирлегендә яшәүчеләр турында да сораштык. Өч авылга 238 хуҗалык исәпләнә. Анда 464 кеше яши икән. Чуаш, рус, татар – төрле милләт вәкилләре бердәм булып гомер кичерә. Әйткәнемчә, җирлектә үзара салым акчасы һәр кешедән 1,5әр мең сум дип билгеләнгән. Барысы да бирә. Димәк, берсе дә авыл язмышына битараф түгел.

– Бездә инвестор – «Кызыл Шәрык». Анда күп кеше эшләми. Кырларны буш тотмыйлар, иген чәчеп, пай җирләренә ашлык бирәләр. Авылда төп эш урыны юк. Өч крестьян-фермер хуҗалыгы бар. Икесе кошчылык буенча шөгыльләнсә, берсе савым сыерлары тота. Авыл кешеләре шунда барып каз йолкый, – ди Равил Хисамов. – Халык терлек асрап, сөт саткан акчага тормышын алып бара. Кемдер – биш, кемдер 13 баш терлек тота. Үзебездә – алты сыер. Сөтнең бәясе җәен 15 сумга төшкән иде, хәзер – 22 сум. Авыл халкы сөт бәясе күтәрелүгә өметләнә.

Сәрия МИФТАХОВА

ҖЫРЛАП ЭШЛИЛӘР

Инженер, машина йөртүче, табиб, полиция хезмәткәре. «Наше время – Безнең заман» XI эшче яшьләр иҗаты фестивале республиканың әнә шул һәм башка һөнәр ияләрен кабат «Пирамида» сәхнәсенә җыйды. Йомгаклау гала-концертында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Иҗатка тартылган эшче яшьләрне берләштергән фестивальдә республиканың 190 оешмасыннан 1,5 меңнән артык үзешчән артист катнашты. Гала-концертка кадәр сайлап алу этаплары Әлмәт, Чаллы һәм Казанда узган.

«Дәүләт өчен иң мөһиме – хезмәт кешесе». Тантаналы чарада катнашучыларны сәламләп, Рөстәм Миңнеханов әнә шулай диде.

– Фестиваль үсә, предприятие җитәкчеләренең ярдәмен күрәбез. Без булдырган система ярдәмендә фестивальгә кушылучы предприятиеләр саны арта. Производство җитәкчеләре моның белән кызыксынмаса, бернәрсә дә килеп чыкмас иде. Аларга эшче коллективлар өчен тиешле шартлар тудырганга рәхмәт. Яшь хезмәткәрләрнең иҗади үсеше өчен бик мөһим бу. Безнең илдә иҗади кешеләр, төрле учреждениеләр күп, әмма мондый проект беркемдә дә юк. Бары бездә генә, Татарстанда, – дип сөйләде республика җитәкчесе.

Татарстан вице-премьеры, сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко фикеренчә, фестиваль уздыру сәнәгатьне үстерүдә һәм эшче һөнәрләрне популярлаштыруда мөһим роль уйный.

– Илебез өчен катлаулы чорда хезмәт коллективлары көчле һәм бердәм булырга тиеш. «Безнең заман» кебек фестивальләр безнең сәнәгатьне тагын да көчлерәк итә. Оештыручыларга зур рәхмәт! – диде министр.

Инженерлар, укытучылар, табиблар, слесарьлар, полиция хезмәткәрләре, электриклар һәм башка һөнәр ияләре бу кичтә үзләрен сәхнә артистлары ролендә сынап карады. Сынап карадылар, дип әйтергә тел дә әйләнми, чөнки алар чын артистлардан кимен куймый. Арттыру түгел, моны барып күрергә кирәк. Араларында хәтта фестивальнең 11 елы дәвамында да сәхнә тотучылар бар. Быелгы гала-концерт Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышланган иде. Катнашучылар республикада яшәүче халыкларның төрлелеген һәм бердәмлеген җыр һәм бию белән күрсәтте.

Фестивальнең яңалыклары да бар: төп җиңүчегә бирелгән бүләкне 1 миллион сумга җиткерделәр, «Зирәклек һәм остазлык» дигән махсус номинация барлыкка килгән. Шулай итеп, Гран-прига СИБУРның «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыяте командасы лаек булды. «Безнең заман герое» дигән махсус призны һәм 500 мең сумлык сертификатны «Юл хәрәкәте иминлеге» учреждениесе алды. «Зирәклек һәм остазлык» дигән яңа номинациядә предприятие җитәкчеләре һәм район башлыклары бүләкләнде. Ә кубокны исә «Түбән Кама Нефтехим» оешмасының генераль директоры Марат Фәләхов алды.

– Безнең иҗади команда – слесарьлар, лаборантлар, электромонтерлар һәм аппаратчылар. Алар предприятиедә хезмәт куя һәм үз талантларын үстерергә дә вакыт табалар. Үзләренең югары һөнәри дәрәҗәләрен яшьләр фестивальдә җиңү яулап исбатлады, – диде Марат Фәләхов.

rais.tatarstan.ru

Ләйсән САФИНА

Авыл

ИГОРЬ ГОРДЕЕВ: «Кызлар белән йөрергә вакыт юк»

Кукмара районының Иске Оча авылында яшәүче Игорь Гордеев һәркөн 17 сыер сава. Хуҗалыкларында 2 тана һәм 7 бозаудан кала, сарык, куян һәм кош-корт та асрыйлар. 22 яшьлек егет шул арада мәдәният йортында да эшләргә өлгерә.

– Шәһәргә бер дә китәсем килми. Кукмара аграр көллиятендә укыганда да көн саен авылга кайтып йөрдем. Укырга киткәнче, сыерларны савып, асларын чистартырга өлгерә идем инде. Кичкә тагын аларны сагынып кайтып җитәсең. Эшем күп, көненә ике-өч сәгать йокласам да, зарлана алмыйм. Җәйләрен иртәнге дүрттә аякта инде мин. Кышын да күп йоклап булмый, – дип сөйли Игорь.

Маллар ярату бабасыннан күчкән егеткә.

– 2007 елда йорт җиткереп башка чыктык. Яңа өйгә күченгәндә, бабай миңа бер бозау бирде. Әнә шуны үстереп, сыер иттек. 7–8 яшемдә маллар карый идем инде. Шул вакыттан бирле гомерем сарайда уза. Шәхси хуҗалыгыбыз әтием исеменә теркәлсә дә, бар эшне үзем башкарам. Иртәдән кичкә кадәр алар янында. 17 сыерның һәрберсенең үз кушаматы бар. Мин аларны, алар мине ярата, – ди Игорь. – Әнием күрше авыл мәктәбендә укыта, әтием Кукмарага барып эшләп йөри. Ике сеңлем бар. Күптән түгел бер туганыбыз вафат булгач, аның ике кызын да тәрбиягә алдык. Бер-беребезне аңлап, тату гына яшибез.

Эре мал янында кош-корт та җитәрлек аларда. Гордеевларда казы да, үрдәге дә ояда бәбкә чыгара.

– Бездә бик күңелле. Мулард, индоүрдәк, кыргый йорт үрдәкләре, цесарка, күркә, йонлы тәпиле тавык, әтәчләргә кадәр бар. Зәңгәрсу йомырка сала торган тавыклар да алдым әле, – ди ул. – Шәхси ярдәмче хуҗалык булып теркәлгәч, дәүләттән дә ярдәм булып тора. Мал азыгы сатып алганда да безгә ташлама каралган. 2020 елда дәүләт ярдәме белән сыерлар өчен кечкенә генә ферма төзегән идек. Малларга 150 төргәк печән, 120 төргәк салам кирәк. Ашлыкны исәпләп торган юк. Барысын да сатып алабыз. Үзебезнең пай җиребез дә бар. Анысын да буш тоткан юк.

Мал тоту – бер хәл, әле бит сөтен дә урнаштырасы бар. Егет аны дәүләткә тапшыра. Җәен литрын 20 сумнан, хәзер инде 26 сумнан җыялар икән. Әлегә кадәр тәүлегенә 200 литрлап сөт сауган. Хәзер кышка таба сыерларның сөте дә кимегән, күбесе буаз да.

Авылда эш булмагач, Иске Очада күпләр читкә барып эшли. Яшьләр китү ягын карый икән. Игорьның моңа бик тә эче поша. Авыл дип янып яши ул. Мәдәният йорты җитәкчесе декрет ялына киткәч, аның урынына Игорьны чакырганнар.

– Читтән торып мәдәният хезмәткәре курсларын үттем. Җырларга бик яратам. «Италмас» удмурт ансамблен җитәклим. Күңелле яшибез. Клубтан кеше өзелми. Җыр-бию генә түгел, махсус хәрби операциядәге егетләргә дип маскировка челтәрләре дә үрәбез, – ди ул. – Кызлар белән йөрергә вакыт юк. Бөтен вакытым маллар янында уза. Миңа җирне, малларны ярата торган кеше кирәк. Терлек санын тагын да арттырасы килә. Киләчәгем авылда минем.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Алсу Идрисова

«СЫЕРСЫЗ ЯШӘП БУЛМАС»

Ун көнләп элек сыерны җибәрдек. Авыл кешесе сыерын чалдырса да, сатса да, әнә шулай «җибәрдек» дип сөйләшә. Бу үзенә күрә сыер малына аерым мөнәсәбәт билгесе булып тора. Асрау җиңел булмаса да, ничә ел гаиләңне сөте-мае белән тукландырган, кысыр калмаган елларында бозавы белән сөендергән сыерың бик якын була шул.

Кайберәүләр бер тапкыр парез булуга яки бер ел кысыр калуга ук, сыерын алыштыра. Кемдер танадан үзе үстерә, кемдер сатып ала. Сыер алыштыру лотерея уенына тиң: отасыңны, оттырасыңны белмисең. Сөтле булыр дип өметләнгәннәре сөтсезгә әйләнә, яман холкы белән хуҗасын имгәтүчеләр дә очрый… Шуңа да күпләр сыер алыштырып уйнау яклы түгел. Без дә шулай. «Сыерыгыз бозаулаган саен егыла бит, ник алыштырмыйсыз инде», – дип киңәш бирүчеләр күп булды. Тик ул турыда уйламадык та. Бердән, холкына ияләнеп беткән, икенчедән, сөте тәмле, куе, өченчедән, бик чиста. Сыртыннан пычракка баткан сыерлар арасында көтүдә дә аерылып тора иде ул. Сүз уңаеннан, аннан алдагы сыерыбызның да кара төсе бик аз, ул да һәрчак сабынлап-мунчалалап юган кебек, тоягына кадәр чип-чиста булып йөрде. Хәтерлим әле, авылның теге очындагы махсус урынга уколга алып барганда, авылдашым Раушанның кунакка килгән ике-өч яшьләрдәге оныгы: «Апай, иң матур сыер синеке», – дип калган иде. Иминиятләштергәндә сыерларны төрле яклап фотога төшерә башлагач, агент кыз да: «Иии, безнең Казандагы кызлар синең сыерыңны карап, хәлдән тайды, бигрәк матур диештеләр», – дигән иде.

«Күз тию малны – казанга, кешене гүргә кертә», – дигән сүзләрдә хаклык бардыр. Ни генә дисәң дә, соңгы ике сыерның да авырудан башы чыкмады. Соңгысында да авырса дәвалату чараларын күрдек, кысыр калса да сабыр иттек. Файда, табыш ягын уйлап асрамадык. Үзебез өчен иде. Быел да, кысыр калса да, әле сөтен бетермәсә, җибәрү уйда да юк иде. Әмма ярты ел сөтсез бура кадәр сыер асрау инде үзең өчен генә дә аклана торган эш түгел шул.

«Сыерны җибәрәм дип, җебисе түгел. Шулай тиешле дип кабул ит. Әнә бер танышларым, әни төсе дип, сыерларын үзе егылып үлгәнче асрады. Сыер нинди әни төсе булсын инде ул?! Ашый алмас хәлгә җиткәнче сыер тилмертүдән әниләренә җиңел булгандыр, дисеңме? Аның киеменме, әйберенме кадерләп саклау вафат булганга берничек тә ярдәм итми, дога гына кирәк аларга», – дип, рәхмәт төшкере, мине алдан нygытучы танышым да булды. Өстәвенә, бер яктан шалтыратып белештек, икенче яктан әйтелгәннән дә алда килеп, алып та киттеләр. Тик ничек кенә булса да, ихатаңнан сыерны соңгы тапкыр чыгарып җибәрү бер дә җиңел түгел. Дөрес, хәсрәт түгел ул. Әмма бик сирәкләр генә күз яшьсез озата. Хәтта ирләр дә.

– Үзебезнең ике сыерны күптән түгел җибәргән идек. Тынычланып кына килә идем, сезнең турыдан үтеп барганда, сыерыгызны машинага менгергән чакка туры килдем… – ди, күз яшьләренә буылып, күршебез.

– Мин бу юлы еларга өлгермәдем. Сыер алырга килүче егетләр бик сизгер булып чыкты, мине абзардан да чыгармадылар, сыерны үзләре алып чыкты, берсе сөйләштереп калды… – дим аңа каршы.

Бер караганда, еш алыштырмасак та, инде мал карау безнең өскә күчкәннән соң гына да дүртенче сыерны озаттык. Дүртесе дүрт төрле китте. Әмма һәркайсының холкы, төсе, сөте, күз карашы, хәтта көтүдән кайту рәвеше дә бүгенгедәй күз алдында. Иң кыены – сыерсыз калган буш абзарга керү. Ун көн үтсә дә, әле аңа тиз генә ияләшеп булмый… Үч иткәндәй, быел сыер ярата торган костер печәне эчтәрәк калган иде, аны җибәреп берничә көн үтүгә, шул печән чыкты. Шуны бозауларга салган саен, «сыерга ашата алмадык» дигән уй күңелне телеп үтә, насыйп булмагандыр, дип үземне юатырга тырышсам да, күзгә яшь туларга бер сәбәп була.

Сыерны җибәргәнне белүгә, әни: «Сыерсыз яшәп булмас, аласыздыр бит?» – дип куйды. Аны да аңлап була, баш түбәсенә күтәреп, кыш буе салам ташыган, җәй буе уфалла өстерәп, печән әзерләгән елларда да сыер асрамый калган кеше түгел бит ул. «Авылда унбиш кеше сыер асрый, калган кырыктан артыгы сыерсыз, сөтсез үлмиләр бит», – дим, аннан да бигрәк үземне тынычландыру өчен. Ә иремә әле сыер абзарындагы әйберләргә тими, сүтми торырга куштым. Дөнья хәлен кем белгән…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ БОЕРЫК

09.11.2023 ел   Казан ш.   №3140-р

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләрен раслау турында

«Дәүләт кадастр бәяләве турында» 3 июль, 2016 ел, № 237-ФЗ Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларына дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү турында» 21.02.2022 ел, № 540-р Татарстан Республикасы; Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгын тормышка ашыру максатыннан чыгып:

1. 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләрен расларга.

2. Бу боерыкны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы рәсми сайтында (https:// mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы рәсми басмаларында – «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Министр Ф.Ә. Әһлиуллин

Приложение
к постановлению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
от 21 ноября 2023 г. № 28/193

Информационное сообщение
о сборе предложений по кандидатурам для дополнительного зачисления в резерв составов участковой избирательной комиссии избирательного участка № 2276, образованного на территории Нижнекамского района Республики Татарстан, участковых избирательных комиссий избирательных участков № 2310, №2317, образованных на территории Новошешминского района Республики Татарстан

Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет сбор предложений по кандидатурам для дополнительного зачисления в резерв составов участковых избирательных комиссий избирательных участков № 2276, образованного на территории Нижнекамского района Республики Татарстан, участковых избирательных комиссий избирательных участков № 2310, № 2317 образованных на территории Новошешминского района Республики Татарстан, в период с 27 ноября по 8 декабря 2023 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов).

Наименование территориальной избирательной комиссии (ТИК)	Адрес территориальной избирательной комиссии
ТИК Нижнекамского района РТ	423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, д. 12, тел.: (8555) 42-49-32
ТИК Новошешминского района РТ	423190, с. Новошешминск, ул. Советская, д. 80, тел.: (843)48-32-32

В резерв составов участковых избирательных комиссий не зачисляются кандидатуры, не соответствующие требованиям, установленным пунктом 1 статьи 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации».

Кандидатуры, в отношении которых отсутствуют документы, необходимые для зачисления в резерв составов участковых избирательных комиссий, в резерв составов участковых избирательных комиссий не зачисляются.

Примечание.

При внесении предложений по кандидатуре в резерв составов участковых избирательных комиссий на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 5 декабря 2012 года № 152/1137-6 «О порядке формирования резерва составов участковых комиссий и назначения нового члена участковой комиссии из резерва составов участковых комиссий».

Постановление Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 5 декабря 2012 года № 152/1137-6 «О порядке формирования резерва составов участковых комиссий и назначения нового члена участковой комиссии из резерва составов участковых комиссий» в актуальной редакции, перечень и образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в разделе «Избирательные комиссии» в подразделе «Резерв составов участковых комиссий» «Дополнительное зачисление в резерв составов участковых избирательных комиссий 2023 г.» https://izbirkom.tatarstan.ru/.

Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан

Приложение
к постановлению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
от 21 ноября 2023 г. № 28/191

Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан о приеме предложений по кандидатурам членов избирательной комиссии с правом решающего голоса в состав территориальной избирательной комиссии Кировского района города Казани Республики Татарстан на вакантные места

В связи с прекращением полномочий членов территориальной избирательной комиссии Кировского района города Казани Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатурам для назначения членов территориальной избирательной комиссии Кировского района города Казани Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 23 ноября по 5 декабря 2023 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатуре в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Приложение
к постановлению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
от 21 ноября 2023 г. № 28/189

Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан о приеме предложений по кандидатуре члена избирательной комиссии с правом решающего голоса в состав территориальной избирательной комиссии Ютазинского района Республики Татарстан на вакантное место

В связи с прекращением полномочий члена территориальной избирательной комиссии Ютазинского района Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатуре для назначения члена территориальной избирательной комиссии Ютазинского района Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 23 ноября по 28 ноября 2023 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатуре в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Бүген бездә кунакта – Арча районының Наласа урта мәктәбе укучылары. Алар, Әниләр көне уңаеннан иң кадерле кешеләренә атап, хатлар язганнар, шигырьләр иҗат иткәннәр. Хатларда наз һәм ярату, шул ук вакытта борчылу да бар.

Алисә ӘСӘДУЛЛИНА,
2 нче сыйныф укучысы

Кадерлик әниләрне!

«Әни» сүзен ишетүгә, күңелдә нииндидер рәхәтлек, җылы хисләр барлыкка килә, шулай бит?! Бу юкка гына түгел. Безнең өчен һәрчак борчылып, кайгырып торучы – Әни. Авыр чакта ярдәм кулын сузып, төпле киңәшен бирүче – Әни. Нинди генә хәл килеп чыкмасын, безнең янда булучы – Әни. Әйе, «әни» исемен йөрткән изге кешеләр һәрчак безнең белән. Һәрвакыт шулай булсын ул! Алар булганда гына без бәхетле һәм тыныч, чөнки тормышның нинди генә авыр чагы килеп чыкса да, юатучы әниләребез бар, Аллаһка шөкер. Без алар каршында баш иеп, РӘХМӘТ әйтергә тиешбез, алай гына да түгел: әниләребезне кайгыртып тору, беркайчан да аларга каршы сүз әйтмәү – безнең төп бурычыбыз.

Әмма, дөресен генә әйткәндә, әниләргә тиешенчә игътибар бирелми безнең заманда. Алар иртәдән кичкә кадәр эштә, аннан арып-талып кайткач та, иң беренче уйлары – безне кайгырту бит. Ашарга әзерлиләр, киләсе көнгә кирәк булган киемнәрне юып, үтүкләп бирәләр. (Үзебез дә үтүкләргә тырышабыз без, әмма әнинеке кебек матур, чиста килеп чыкмый...) Шулай эшләгән арада: «Көнең ничек үтте, улым, кызым?» – дип, мәктәптә үткәргән вакытыбыз турында да кызыксынып алалар. Ә без... әнигә ашатканы өчен «рәхмәт» әйтәбез дә үз эшебезне дәвам итәбез. Шундый якын, газиз кешеләребезне кочаклап: «Мин сине яратам, әнием», – дип әйтү бик авыр түгел бит. Әмма эшләмибез инде шуны. Нигә? Җавапны бирәү дә белми. Әниләребезгә күп тә кирәкми: без исән-сау булсак, аларны кайгыртып торсак, шул җиткән. Бу гади эшне генә эшли алабыз бит. Менә бу язманы укыгач, әниләрегезгә ярату сүзләрен әйтегез әле. Аларның күңеле шундук эреп китәр. Әйтте диярсез.

Озын сүзнең кыскасы, әни – бу дөньядагы иң кадерле, илаһи зат. Нинди генә авырлык килеп чыкса да, ул безнең белән. Шуның өчен без аны кайгыртып, саклап-яклап торырга тиешбез. Озакламый Әниләр көне җитә. Бу бәйрәмдә алар янында булсак иде. Әниләр көне уңаеннан Арча районы Наласа урта мәктәбендә белем алучы егет һәм кызларның да җиткерәсе теләкләре, рәхмәт сүзләре бар. Аларның иҗат җимешләре белән танышырга чакырабыз сезне!

Әнвәр МӨХЕТДИНОВ,
11 нче сыйныф укучысы

Минем әнием бик уңган. Ул тәмле итеп пешерә, бәйли, тегә, чигә, күп итеп гөлләр, яшелчәләр үстерә. Кыскасы, бар эшкә дә өлгерә. Мин әниемә сокланам һәм аның белән горурланам.

Ралинә БИКМУЛЛИНА, 3 нче сыйныф укучысы

Әни – бала өчен иң мөһим кеше. Аның баласына булган мәхәббәтен сүзләр белән генә әйтеп бетереп булмый, минемчә. Ана йөрәгеннән чыккан сүзләр – иң җылы сүзләр. Алар күңелне күтәрә, йөзгә елмаю кундыра, көч өсти, без үзебезне кирәкле итеп хис итәбез. Әниемнең «алтыным», «күз нурым» дигән сүзләре бигрәк тә якын. Миңа моңсу булганда, әнием һәрчак дөрес сүзләр таба. Шатлыклы вакыйгаларны да әни белән бүлешәсе килә, чөнки ул кирәк чакта булыша, синең эш нәтиҗәләреңә сөенә белә. Нииндидер кыенлык килеп чыкканда, мин борчылмыйм, чөнки беләм: янымда терәгем – әнием бар. Минем аңа булган мәхәббәтем чиксез! Ул миңа бик кадерле!

Азалия ГАБДРАХМАНОВА,
11 нче сыйныф укучысы

Әниләр төрле була. Мәсәлән, безнең әниебез бик матур, шәфкатьле, бөтен кешеләргә игелекле һәм эш сөючән. Ул безнең өчен бөтен көчен биреп яши. Әлбәттә, безне бик ярата. Мәктәптән кайтуыбызны тәмле ризыклар пешереп көтеп тора. Ул – бик оста куллы: бәйли дә, чигә дә, тегә дә. Мәктәптәге чараларда да актив катнаша.

Без әниебезне бик яратабыз, аның белән горурланабыз. Һәркемнең дә безнеке кебек әнисе булуын телим.

Алисә АБДУЛЛИНА, 4 нче сыйныф укучысы

«Әни – ...»

«... мине аңлаучы, авыр вакытларда һәрчак янымда булып, төпле киңәшләрен бирүче. Бала белән ана арасында ышанычлы мөнәсәбәтләр булырга тиеш». *(Гүзәлия СӘЛӘХЕТДИНОВА, 9 нчы сыйныф укучысы)*

«... минем өчен иң кирәкле кеше. Мин әниемне бик яратам, аны һәрвакыт шатландырырга тырышам». *(Айнур ГАРИПОВ, 10 нчы сыйныф укучысы)*

«... һәр бала өчен иң сөйкемле, иң кадерле кеше. Әниләре булганнар – бәхетле кешеләр. Мин үземне бик бәхетле дип саныйм». *(Ислам ШӘМСИЕВ, 10 нчы сыйныф укучысы)*

«... безгә, өч баласына, гомер биргән, төн йокысын йокламыйча үстергән. Әни – безнең өчен борчылучы, уңышларыбызга иң беренче булып сөенүче, авыр минутларда ярдәм итүче иң кадерле кешебез». *(Илфар ВӘЛИЕВ, 10 нчы сыйныф укучысы)*

Эльвина САДЫЙКОВА,
1 нче сыйныф укучысы

Кеше тормышында иң бәхетле, иң сөенечле мизгел – якты дөньяга мәхәббәт җимешләре – сабыйлары туудыр. Мин дә әниемне бәхетле итеп, дөньяга беренче бала булып туганмын.

Әни минем өчен бик кадерле. Мин күп нәрсәләрне зирәк һәм акыл туплаган шушы якын кешемнән өйрәнәм. Без йокыдан торуга тәмле ризыклар, чиста кием – бар да әзер. Әни эш эшләгәндә дә төрле вакыйгалар, хикәятләр сөйләп, безгә акыл, тәрбия бирә белә, эшкә өйрәтә.

Әни – һәр яктан уңган кеше. Ул сабыр да, тыйнак та. Авырган чакларда аның ягымлы тавышы, йомшак куллары дәва бирә кебек. Мин әниемә кулдан килгән кадәр ярдәм итәм. Аның борчылуын һич кенә дә теләмим.

Хәлил ВӘЛИЕВ,
10 нчы сыйныф укучысы

Әниләр көне белән!

Әгәр кышкы буранда юл салучы булмаса,
Никтер генә күңелеңне сары сагыш чорнаса,
Иң беренче яннарыңда күрергә теләр кешең,
Лалә чәчәгедәй назлы – ул бит синең Әниең.
Ә бервакыт тормышың шатлыкларга уралса,
Рәхәт, бәхет бар дөньяңны синең урап алса,
Кечкенәдән кеше иткән әниеңне онытма,
Өметләрен акла аның, намусыңны югалтма.
Надан затлар очрап, башкаеңны бутаса,
Егылды бу, абынды, дип дошманнар үртәп торса,
Бел: әниең догалары һәрчак ярдәмгә килер,
Еллар, юллар узсалар да, ул сине саклап йөрер.
Ләкин шуны онытма: ничә яшьтә булса да,
Әниләрен кадерләргә тиештер һәрбер бала!
Никадәр рәхмәт әйтсәк тә, ул әле бик аз була!

Зилә ГАБДРАХМАНОВА,
11 нче сыйныф укучысы

Минем әниемнең исеме – Алсу. Ул безгә тәмле итеп ашлар пешерә, дәресләребезне хәзерләргә булыша. Өйдә әни булганда гына өй нурлы, җылы. Ә мин әниемә бакча эшләрендә бик теләп булышам, кыш көннәрендә кар көрим. Әни белән бергә эшләү рәхәт тә, күңелле дә.

Кәрим ГАТАУЛЛИН, 3 нче сыйныф укучысы

«Әниемнең җылы кочагы»

Әни! Җир йөзендә иң матур сүз шул. Ул – һәр кеше әйтә торган беренче сүз һәм дөньядагы барлык телләрдә дә бердәй ягымлы яңгырый. Әни йөрәге –иң тугрылыклы һәм сизгер йөрәк. Аңарда баласына булган мәхәббәт беркайчан да сүнми.

Әни – безнең иң кадерле кешебез! Аның исеме – Филсинә. Кечкенәдән тырыш бала була. Мәктәпне бары тик «5ле» билгеләренә генә тәмамлап, укытучы һөнәрен үзләштергән. Әниебез безнең өчен һәрьяктан үрнәк. Нинди эшкә тотынса да, ул аны җиренә җиткереп башкара. Безне дә гадел булырга, чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтә. Өйдә дә, эштә дә барысына да өлгерә, безне гел тәмле ризыклар белән сыйлый. Без дә әнигә булышырга тырышабыз. Аның кушканнарын тиз генә эшләп куябыз.

Әнинең җылы карашы, көләч йөзе бөтен өйне җылыта. Шуңа күрә, әнинең йөзе һәрвакыт көлеп торсын өчен, безгә дә тырышып укырга кирәк. Әниебезнең җылы кочагына сыенып, мактау сүзләре ишетү бигрәк тә рәхәт бит.

Әниләребезне саклыйк, яклыйк, аларга авырлык китермик, һәрвакыт сүзләрен тыңлап, ярдәм итик! Алар да безнең белән горурлансыннар!

Илмаз ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН, 4 нче сыйныф укучысы,
Алмаз ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН 7 нче сыйныф укучысы

Минем әнием – иң ягымлы, иң матур әни. Ул бик тырыш. Һөнәре буенча –пешекче. Безгә тәмле ризыклар пешерә. «Әни» дип әйтү – бәхет бит ул! Авыр чакларыбызда да, шатлыклы минутларыбызда да без әниләребезнең җылы кочагына сыенабыз. Йомшак куллары белән башыңнан бер сыйпаса, бөтен авыруларың, борчуларың беткән кебек була. Әнә шундый тылсымлы көчкә ия ул Ана дигән изге зат.

Динә ТӨХБӘТУЛЛИНА, 6 нчы сыйныф укучысы

«Әни» дигән изге сүзне кеше үз гомерендә бик күп тапкыр кабатлый. Һәр кешегә дә бу сүз таныш һәм якын. «Әнием!» – дип әйтүгә, безнең йөзебездә елмаю барлыкка килә.

Бөтен кешегә дә үз әнисе кадерле. Мин дә әниемне яратам һәм хөрмәт итәм. Әниемнең исеме – Рәмзия. Аңа 38 яшь. Ул күзне алмаслык матур, аның гүзәллегенә сокланып туймаслык. Әнием миңа гел яхшылык кына тели, мине төрле начарлыклардан саклый. Мин әниемнең кадерен белеп яшим, ансыз миңа бу дөньяда бик кыен булыр иде. Һәр бала да әнисен хөрмәт итеп яшәргә тиеш.

Мин әниемне бик яратам. Аңа авыр сүз әйтмим, йөзенә кызыллык китермим. Мин генә түгел, һәр бала да әнисенә карата шундый булырга тиеш. Бу авыр дөньяда әнинең ярдәме булмаса, бик кыен булыр иде. Һәр балага да әнисенең яратуын тоярга насыйп булсын!

Сәрия СИРАҖИЕВА, 10 нчы сыйныф укучысы

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Мәрьям КОДИРОВА,
1 нче сыйныф
укучысы

Мин әниемне өзелеп яратам. Серләремне аңа сөйлим. Аның һәр әйткән сүзен тыңлыйм, киңәшләрен үтим. Мин әнием булу белән бик бәхетле. Ә бит күпме ятим балалар бар. Аларның да бәхетле буласылары киләдер.

Әнием – оста пешекче. Ул төрле кабымлыклар, тортлар ясый. Әнием үзенең эшен бик ярата. Аның куллары алтын. Мәңге яшә, әнием!

Әмир ӘГЪЛИУЛЛИН, 5 нче сыйныф укучысы

Мин әниемне бик яратам. Әнием – өебезнең нуры. Ул пешекче булып эшли. Өстәлебез төрле-төрле тәмле ризыклар белән тулып тора. Әнием кул эшенә дә бик оста. Матур башмаклар, оекбашлар бәйли. Мин әнигә озын гомер телим. Җир йөзендәге бер генә әни дә авырмасын!

Әминә ӘГЪЛИУЛЛИНА, 3 нче сыйныф укучысы

Нинди генә авыр
чакларда да
Әни «балам» диеп җан
ата.
Шатлыкларны үзенеке
итә,
Борчуларны куып тарата.

Балалары авырганда алар
Төннәр буе керфек какмыйлар.
Начарлыклар, авыр сүз тидерми,
Уяулыкны һәрчак саклыйлар.

Бармы тагын җирдә әниләрдәй
Уңган, сабыр, тыйнак кешеләр?!
«Балам! Йөрәк парәм!» – диеп,
Безнең өчен янып яшиләр.

Әмир ТӨХФӘТУЛЛИН,
10 нчы сыйныф укучысы

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары –
ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 356

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+